СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.05.2021 с. Татарское Бурнашево № 08-54

«Татарстан РеспубликасыЮгары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советы карары проекты турында

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44нче ст. һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7нче ст, Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән карары проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итеп, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча киләсе составта эшче төркем төзергә:

- эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин;

– эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Р.А.Ильичева;

Эшче төркем әгъзалары:

- Бочков Сергей Михайлович –2 нче номерлы Бурнаш сайлау округы депутаты;
- Лавонин Александр Викторович - 3нче номерлы Бурнаш сайлау округы депутаты;

- Муравьева Любовь Павловна – Татар Бурнашы авыл китапханәсе мөдире.

3. Бурнаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Карары проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2нче кушымта).

4. Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3нче кушымта).

5. Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставы буенча халык алдында тыңлауларны 2021нче елның 7нче июнендә 10.00 сәгатьтә Татар Бурнашы авылы, Советская урамы, 62нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында үткәрергә.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Совет рәисе,<br>
Югары Ослан муниципаль районы<br>
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советының
2021нче елның 21нче маеннан
08-54нче карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 6нчы статьясындагы 1нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 16нчы пунктча өстәргә:

«16) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру».

2. Уставның 24 статьясындагы 3 пунктының 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле тәкъдимнәр өстәргә:

«Торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның җыены торак пункт территориясенең бер өлешендә дә үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә мәнфәгатьләре бердәмлеге критериеннән чыгып билгеләнә».

3. Уставның 50 статьясындагы 1 пунктының 8 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

« - алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыра»;

4. Уставның 81 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«81 Статья. Җирлек гражданнарының үзара салым акчасы.

Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, саны җирлек составына керүче һәм түләү күләме киметелергә мөмкин булган җирлек халкының (торак пунктның яисә аның территориясенең бер өлешенең) гомуми санының 30 процентыннан артыграк була алмаган гражданнарның аерым категорияләреннән тыш, җирлек составына керүче барлык җирлек (торак пункт яисә аның территориясенең бер өлеше) өчен абсолют зурлыкта билгеләнә.

Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә».

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш  авыл җирлеге Советының
2021нче елның 21нче маеннан
08-54нче карарына

2нче кушымта

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУРНАШ  АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Бурнаш авыл җирлеге Советының  Карары проектына тәкъдимнәр 2021нче елның 4нче июненә кадәр, авторның яшәү урыны турында мәгълүматны күрсәтеп, язма рәвештә кертелә. Тәкъдимнәр мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән көннән алып Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советына эшче төркем секретаре Ильичева Р.А шимбә һәм якшәмбе көннәреннән тыш һәр көнне 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр  422594, Татар Бурнашы авылы, Советская урамы, 62нче йорт адресы буенча  кабул ителә. Белешмәләр өчен телефон: (884379) 36245

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советының
2021нче елның 21нче маеннан
08-54нче карарына

3нче кушымта

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАР КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча: 422594, Татар Бурнашы авылы, Советская урамы, 62нче йорт Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Башкарма комитетында Р.А. Ильичевага шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» тамгасы белән) бирелә.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советына язмача гариза биргән авыл халкы үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнаша.

3. Халык тыңлауларында халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка, җирлекнең барлык кызыксынган халкы катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланырга 30 минут кала башлана.

5. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументлау өчен чакырыла.

6. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

7. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Катнашучылар тарафыннан ачык тыңлауларны уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин